ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 23.03.2023 КАРАР
320

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгълүмати элмә такталар урнаштыру, элмә такталар урнаштыруның дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 1393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 1415 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгълүмати элмә такталар урнаштыру, элмә такталар урнаштыруның дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 1393 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 3.3 бүлегендәге 3.3.2 пунктының 3.3.2.1 пунктчасындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Элетрон формада гаризаны формалаштырганда, мөрәҗәгать итүче гаризаның электрон формасы кырларын тутырганнан соң, форматлы-логик тикшерү бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан электрон формадагы гаризаның ялгыш тутырылган кыры ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүләмати хат аша хәбәр ителә.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.А. Мусаев

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 00A3E71B096428C7D14E82404E46486D21
Владелец: Мусаев Руслан Амирах Оглы
Действителен с 13.04.2022 до 07.07.2023